ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.01.2026 № 70

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Опекунга яисә попечительгә опекага алынган затның мирас хокукларына керүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 16 июлендәге 1534 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Опекунга яисә попечительгә опекага алынган затның мирас хокукларына керүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 16 июлендәге 1534 номерлы карарына (2018 елның 03 октябрендәге N 2155 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Опекунга яисә попечительгә опекага алынган затның мирас хокукларына керүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү административ регламентының 5 бүлеге 5.1. пунктында 3 пунктчасындагы "каралмаган документларны" сүзләрен "бирелүе яисә гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яисә мәгълүматны яки гамәлләрне башкару";

1.2. 5 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 5.7.1. һәм 5.7.2 пунктчалар белән тулыландырырга:

"5.7.1. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк тарафыннан дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган хокук бозуларны кичекмәстән бетерү максатларында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенә һәм дәүләт яисә муниципаль хезмәт алу максатларында мөрәҗәгать итүчегә алга таба кылырга кирәкле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7.2. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә."

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып халыкка җиткеререргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 00F37EFECAF99452BE23BE7D3B3145FA83
Владелец: Хакимуллин Рамиль Фатихович
Действителен с 01.11.2024 до 25.01.2026

Р.Ф. Хәкимуллин